**Республика Татарстан**
**СОВЕТ**
**ЛЯКИНСКОГО СЕЛЬСКОГО**
**ПОСЕЛЕНИЯ САРМАНОВСКОГО**
**МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

ул. Школьная, д. 1,
с. Ляки, 423366.
Телефон: (85559) 4-66-16
E-mail: Lkn.Sar@tatar.ru

**Татарстан Республикасы**
**САРМАН МУНИЦИПАЛЬ**
**РАЙОНЫ ЛӘКЕ**
**АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ**
**СОВЕТЫ**

Мәктәп урамы, 1 йорт,
Ләке авылы, 423366.
Телефон: (85559) 4-66-16
E-mail: Lkn.Sar@tatar.ru

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

2021 елның 25 ноябре 17 номерлы

"Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Ләке авыл җирлегенең 2022 елга һәм 2023- 2024 елларга план чорына социаль-икътисадый үсеш фаразы турында"

Россия Федерациясенең Бюджет кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясы, Татарстан Республикасының Бюджет кодексы нигезендә, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының «Ләке авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына таянып, башкарма комитет җитәкчесенең «Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Ләке авыл җирлегенең 2022 елга һәм 2023- 2024 елларга план чорына социаль-икътисадый үсеш фаразы турында» чыгышын тыңлап фикер алышканнан соң, Сарман муниципаль районының Ләке авыл җирлеге советы карар итте:

1. «Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Ләке авыл җирлегенең 2022 елга һәм 2023- 2024 елларга план чорына социаль-икътисадый үсеш фаразы турында» мәгълүматны игътибарга алырга (1нче кушымта).
2. Сарман муниципаль районының Ләке авыл җирлеге башкарма комитетына Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Ләке авыл җирлегенең 2022 елга һәм 2023-2024 елларның планлы чорына социаль-икътисадый үсеш фаразын үтәүне тәэмин итәргә.
3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Сарман муниципаль районының Ләке авыл җирлеге башлыгына йөкләргә

Ләке авыл
җирлеге Советы рәисе Л.И.Шәрипова

Приложение 1

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Ләке авыл җирлегенең 2022 елга һәм 2023- 2024 елларның план чорына социаль-икътисадый үсеш фаразы

| Күрсәткеч исеме | Үлчәү берәмлеге | 2019 | 2020 | 2021 | 2022 | 2023 | 2024 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | хисап | хисап | бәяләмә | фараз | фараз | фараз |
| Халык саны | кеше | 392 | 392 | 392 | 392 | 392 | 392 |
| Узган елга карата үсеш темпы | % | | | | | | |
| Мөгезле эре терлекләр саны | баш | 146 | 132 | 125 | 120 | 120 | 120 |
| Узган елга карата үсеш темпы | % | | | | | | |
| Инвестицияләр | мең сум | 1100 | 1100 | 1100 | 1100 | 1100 | 1100 |
| Узган елга карата үсеш темпы | % | | | | | | |
| Торак тапшыру | кв.м. | 100 | 90 | 80 | 80 | 80 | 80 |
| Узган елга карата үсеш темпы | % | | | | | | |
| Хезмәткә түләү фонды | мең сум | 8090,6 | 8047,8 | 8254,2 | 8794,2 | 8994,2 | 9054,2 |
| Узган елга карата үсеш темпы | % | | | | | | |
| Уртача айлык хезмәт хакы | сум | 29313,8 | 33532,5 | 34392,5 | 36642,5 | 37475,8 | 39711,4 |
| Хезмәткәрләрнең исемлек буенча уртача саны | кеше | 23 | 20 | 20 | 20 | 20 | 19 |
| Эшкуарлар саны (КФХ,ШЭ) | кеше | 1 | 1 | 1 | 1 | 1 | 1 |
| Эшсезләр саны | кеше | 2 | 0 | 0 | 0 | 0 | 0 |

Ләке авыл җирлеге хисапчысы Тимирова Р.В.

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Ләке авыл җирлегенең 2022 елга һәм 2023- 2024 елларның план чорына социаль-икътисадый үсеш фаразына аңлатма язуы

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Ләке авыл җирлегенең социаль-икътисади үсеш фаразына керем чыганакларын һәм бюджет чыгымнарының статьяларын формалаштыру өчен кирәк булган төп макроикътисади күрсәткечләрне үз эченә ала.

2022-2024 елларга Сарман муниципаль районы Ләке авыл җирлегенең социаль-икътисади үсеш фаразы Россия Икътисадый үсеш министрлыгы тәкъдим иткән 2022-2024 елларга Россия Федерациясе икътисады эшчәнлегенең сценар шартларының база варианты нигезендә эшләнде, Сарман муниципаль районы Ләке авыл җирлегенең 2021 елның көтелә торган нәтиҗәләрен һәм 2022-2024 елларда икътисад һәм социаль өлкә үсеше тенденцияләрен бәяләүне исәпкә алып, 2022-2024 елларга Россия Икътисадый үсеш министрлыгы тәкъдим иткән инфляция һәм индекс-дефляторлар күрсәткечләрен кулланып эшләнде.

2022-2024 елларда «Urals» нефтенә бәяләрнең баррель өчен 54,2-56,2 АКШ доллары дәрәҗәсендә уртача динамикасы фаразлана.

2022 елда долларның уртача еллык курсы АКШ доллары өчен 71,5 сум, 2023 елда АКШ доллары өчен 72,4 сум булыр дип фаразлана. 2024 елда, Россия Икътисадый үсеш министрлыгы фаразына караганда, доллар курсы АКШ доллары өчен 72,4 сум тәшкил итәчәк.

Ләке авыл җирлеге составына Ләке, Дружба, Фермы Сәүкле, Языково авыллары керә.

2022 елга Сарман муниципаль районы Ләке авыл җирлегендә халык саны 392 кеше, 2023 елга – 392 кеше, 2024 елга – 392 кеше тәшкил итәчәк.

Авыл хуҗалыгын үстерү фаразы «Нөркәй» агрофирмасы ҖЧҖенең булган потенциалын һәм килеп туган үсеш тенденцияләрен, фермер һәм шәхси ярдәмче хуҗалыкларны, шулай ук «Агросәнәгать комплексын үстерү» һәм «Шәхси ярдәмче хуҗалыкларны үстерү» программаларын гамәлгә ашыру буенча билгеләнгән чараларны исәпкә алып эшләнгән.

Хәзерге вакытта авыл җирлеге территориясендә «Нөркәй» агрофирмасы ҖЧҖ һәм КФХ Андров М.А. эшчәнлек алып баралар.

2021 елда авыл хуҗалыгы продукциясен җитештерү күләме 688 900 мең сумнан артык тәшкил итәчәк. 2022 ел фаразына караганда, продукция күләме 723 345 мең сум тәшкил итәчәк, 2023 елда – 5% ка артачак һәм 759 512 мең сум тәшкил итәчәк, 2024 елда – 5% ка артачак һәм 797 488 мең сум тәшкил итәчәк.

2021 елда төп капиталга инвестицияләр 1 млн. сум күләмендә булды. 2022-2024 елда үсеш темпы 101% тәшкил итәчәк һәм 1,1 млн. сум тәшкил итәчәк.

2022-2024 елларда якынча 240 квадрат метр торак файдалануга тапшыру планлаштырыла.

2021 елда хезмәт хакы фонды 8254,2 мең сум тәшкил итәчәк.

2022 елга хезмәт хакы фондының фаразланган күрсәткече – 8794,2 мең сум, 2023 елда – 8994,2 мең сум, 2024елда- 9054,2 мең сум тәшкил итәчәк.

Хезмәткәрләр саны уртача 20 кеше тәшкил итә.

2021 елда уртача айлык хезмәт хакы 34392,5 сум тәшкил итәчәк. 2022 елга фараз буенча ул- 36642,5 сум, 2023 елда- 37475,8 сум, 2024 елда 39711,4 сум тәшкил итәчәк.

2022 елга эшмәкәрләр саны (КФХ) 2 кеше тәшкил итәчәк, 2023 елга-2, 2024 елга-2 кеше.